Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советының алтынчы утырышы

Күн авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

22 март, 2021 ел                                                                                № 19

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 28 октябрендәге 138 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан **Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 28 октябрендәге 138 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 5 пунктта дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм физик затлар мөлкәтенә салымны 2020 елның 1 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы                                                    Р.Г. Баһауов

СОВЕТ КОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000842